МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 36/0

"28" 03 2019

БОЕРЫК

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен җылы белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары булган күпфатирлы йортларны һәм торак йортларны җылыту буенча коммуналь хезмәттән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 132/0 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен җылы белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары булган күпфатирлы йортларны һәм торак йортларны җылыту буенча коммуналь хезмәттән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 132/о номерлы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2013 елның 20 маендагы 62/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) боерыгына кертелә торган үзгәрешләрне (кушымтада бирелә) расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы мөдире Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрының беренче урынбасары А.М. Фроловка йөкләргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2019 елның
«28» 03 №36/о
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен җылы белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары булган күпфатирлы йортларны һәм торак йортларны җылыту буенча коммуналь хезмәттән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 132/о номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен җылы белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары булган күпфатирлы йортларны һәм торак йортларны җылыту буенча коммуналь хезмәттән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 132/о номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын билгеләү һәм ачыклау кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 23 маендагы 306 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:»;

5 пунктта «министр урынбасарына йөкләргә» сүзләрен «министрның беренче урынбасарына йөкләргә» сүзләре белән алмаштырырга;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен 1999 нчы елдан соң төзелгән, җылылык белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары булган күпфатирлы һәм торак йортларда торак урыннарны җылыту буенча коммуналь хезмәттән файдалануның аталган боерык белән расланган нормативларына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Минзәлә | | 0,01664 | 0,01651». | | | | | |